**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында гражданнар җыены карары**

**13 .12. 2023** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пунктында гражданнар җыены:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең Удельное Нечасово торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 1000 (бер мең) сум күләмендә гражданнарның үзара салым салуын кертергә, I төркем инвалидлары, төрмәдә утыручы гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар; гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар, һәлак булган махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр).

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Удельное Нечасово торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

**Җитәкче** **М.Ю. Никонорова**